Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге
Бутаиха торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

«24» октябрь 2024 ел № 81

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мамык авыл җирлеге Бутаиха поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ :

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Бутаиха поселогы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына һәйкәл төзү.

Халык җыенында рәислек итүче: В.В. Рыжков

Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков